КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 июль г.Казань № 508

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 21 июнь, 484 нче карары белән расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 484 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 ноябрь, 1035 нче, 2022 ел, 10 сентябрь, 977 нче, 2023 ел, 10 май, 582 нче, 2023 ел, 2 август, 933 нче, 2023 ел, 19 декабрь, 1643 нче, 2024 ел, 21 октябрь, 902 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазландыру эшләрен башкаручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә яңадан җиһазландыруны башкаручы затлар тарафыннан күрсәтелгән эшләргә транспорт чаралары хуҗаларына ташламалар бирү белән бәйле алынмаган керемнәрен кире

кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II һәм III бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Заявканы карау датасына һәм субсидия бирү турында килешү төзү торышы буенча сайлауда катнашучыга туры килергә тиешле таләпләр:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентатан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмый яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридки зат булган сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында, индивидуаль эшкуар турында мәгълүматлар булмау;

2.2. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлап алуда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән әлеге таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Табигый газны (метанны) мотор ягулыгы сыйфатында куллануга ТЧ яңадан җиһазлау эшләрен түбәндәге таләпләрне үтәүне исәпкә алып гамәлгә ашыру сайлап алу критерие булып тора:

ТЧ хуҗасы Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән (ТЧ хуҗасы булган лизинг бирүчедән тыш) яисә Татарстан Республикасы территориясендә ТЧ эксплуатацияли;

ТЧ яңадан җиһазлау агымдагы елга кадәрге елның IV кварталыннан да иртәрәк гамәлгә ашырылмаган, һәм сайлауда катнашучы әлеге Тәртип кысаларында ТЧ хуҗасына әлеге ТЧга элегрәк күрсәтелгән ташлама бирмәгән;

2026 елдан башлап яңа двигатель урнаштырганда (ТЧ ремоторизацияләү) куела торган двигатель яңа (элек кулланылышта булмаган), ул табигый газда (метанда) эшләү өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе территориясендә җитештерелгән булырга тиеш;

яңадан җиһазландыру пункты тарафыннан башкарыла торган эшләргә минималь гарантия срогы - 1 ел яки 30 000 км (кайсы иртәрәк булуга бәйле);

ТЧ хуҗасына яңадан җиһазландырылган ТЧ эксплуатацияләү һәм аңа хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре турында инструктаж үткәрелде;

кулланыла торган газ баллоны җайланмасы, аның компонентлары, комплектлау әйберләре һәм сайлап алуда катнашучы тарафыннан башкарыла торган ТЧ яңадан җиһазландыру эшләре Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чараларының куркынычсызлыгы турында» техник регламентына (Федераль кагыйдәләр нигезендә) туры килә;

сайлап алуда катнашучы һәм ТЧ хуҗасы арасында төзелгән ниятләр турындагы килешүнең күчермәсе (сайлап алуда катнашучы тарафыннан ТЧ хуҗасы һәм «Газпром

газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән яки табигый газ (метан) сатуны гамәлгә ашыручы башка оешма белән өчьяклы килешү төзелгән очракта);

ЯҖТХП тикшерү буенча ведомствоара комиссиянең федераль кагыйдәләр таләпләренә туры килүенә уңай карары булу (алга таба - ведомствоара комиссия), шул исәптән:

мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) куллануга ТЧ яңадан җиһазлау өчен кимендә ике пост булу һәм йөк ТЧ һәм автобусларны мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) куллануга  яңадан җиһазлау өчен кимендә бер махсуслаштырылган пост булу (мондый транспорт чараларын яңадан җиһазлау башкарылган очракта);

кимендә өч җиңел транспорт чарасы булу һәм клиентлар зонасы өчен кимендә 10 кв.метр мәйданлы туплау мәйданчыгы булу;

кысылган табигый газ белән эшләү өчен автомобильләрне яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрүгә  ярашканлык сертификаты булу;

субсидия бирү елына кадәрге елның 1 гыйнварыннан кимендә 10 берәмлек транспорт чарасы яңадан җиһазлау тәҗрибәсе булу.

2.4. Мотор ягулыгы сыйфатында табигый газны (метанны) куллануга ТЧ яңадан җиһазлаганда урнаштырыла торган газ баллоны җайланмасы, аның компонентлары һәм комплектлаучылар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

газ баллон җиһазларының билгеләнгән тибы БМО Европа икътисади комиссиясенең «Рәсми раслауга кагылышлы бертөрле күрсәтмәләр: II. Двигательләрендә СТГ (сыекландырылган табигый газ) кулланыла торган механик транспорт чараларында урнаштыру өчен билгеләнгән махсус модификацияләнгән сыекландырылган сыек газ системалары» 2003 елның 30 октябрендәге 115 номерлы Кагыйдәләр  таләпләренә туры килә, бу тиешле сертификат белән раслана;

җиһазларның файдаланылган элементлары (компонентлары) БМОның Европа икътисад комиссиясенең 110 номерлы «Рәсми раслауга кагылышлы бердәм күрсәтмәләр: I.  Двигательләре кысылган табигый газ һәм/яки сыекландырылган табигый газ белән эшли торган механик транспорт чараларының махсус җайланма элементлары; II. Транспорт чараларының двигательләрендә кысылган табигый газ (КТГ) һәм/яки сыекландырылган табигый газ (СТГ) куллану өчен рәсми расланган типтагы махсус җайланма элементларын урнаштыруга карата транспорт чараларын» кагыйдәләре таләпләренә туры килә:  , бу тиешле сертификат белән раслана;

урнаштырылган җайланма яңа (элек кулланылышта булмаган) булырга тиеш;

газ баллоны саклау җайланмасы белән автомат вентиль белән җиһазландырылган, билгеләнгән газ баллонын чыгару срогы Федераль кагыйдәләргә 3 нче кушымтаның 1 пунктындагы бишенче абзацына туры килергә тиеш;

Федераль кагыйдәләргә 3 нче кушымтаның 1 пунктындагы алтынчы абзацы нигезендә газ баллоны үзебездә җитештерелгән булырга тиеш.

2.5. Ведомствоара комиссия составы, шулай ук ЯҖТХП тикшерүе тәртибе вәкаләтле орган боерыгы белән билгеләнә.

Ведомствоара комиссия төзү турында вәкаләтле орган боерыгында (алга таба - Комиссия төзү турында боерык) түбәндәгеләр булырга тиеш:

ведомствоара комиссия составы;

ведомствоара комиссия әгъзаларының вәкаләтләре;

ЯҖТХП өчен сайлап алу критерийлары.

Комиссия төзү турында боерык кабул ителгән көненнән алып өч эш көне эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/) (алга таба - вәкаләтле орган сайты) урнаштырыла.

2.6. Ведомствоара комиссиянең уңай карарын алу өчен сайлап алуда катнашучылар әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш. ЯҖТХП әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе (туры килмәве) ел саен ведомствоара комиссия тарафыннан билгеләнә, аның составы вәкаләтле орган боерыгы белән расланган. Федераль кагыйдәләр таләпләренә туры килүгә тикшерүне узу өчен сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

а) гамәлгә кую документларының күчермәләре;

б) тикшерү үткәрү аена кадәрге айның 1 числосына бирелгән юридик затларның яисә индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

в) салым органының тикшерү үткәрелгән айга кадәрге айның 1е хәленә карата бирелгән салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмауны раслый торган белешмә кәгазен;

г) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сынау лабораторияләре белән хезмәттәшлек турында гамәлдәге шартнамә күчермәсе;

д) Идел буе федераль округы территориясендә урнашкан баллоннарны яңадан тикшерү пунктлары белән хезмәттәшлек турында гамәлдәге шартнамә күчермәсе;

е) ЯҖТХП кысылган табигый газ белән эшләү өчен автомобильләрне яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрүгә яраклылык сертификаты һәм тикшерү үткәрелгән елга кадәрге елның 1 гыйнварыннан кимендә ун берәмлек транспорт чарасын яңадан җиһазландыру тәҗрибәсе булуын раслый торган документлар;

ж) «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм (яки) газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча стимул бирү характерындагы программаларны тормышка ашыруда катнашучы, табигый газ (метан) сатуны гамәлгә ашыручы башка оешма белән төзелгән партнерлык килешүе (алга таба – партнерлык килешүе);

з) ЯҖТХП хезмәткәрләренең кысылган (сыекландырылган) табигый газда эшләү өчен автомобильләрне яңадан җиһазлау эшләрен уздыруга квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;

и) яңадан җиһазландыру өчен кимендә ике пост һәм, йөк ТЧ һәм автобусларны яңадан җиһазландыруны гамәлгә ашырган очракта, мондый ТЧ яңадан җиһазландыру өчен кимендә бер махсус пост булуын раслый торган документлар;

к) кимендә өч җиңел транспорт чарасы һәм клиентлар зонасы өчен кимендә 10 кв.метр мәйданлы туплау мәйданчыгы булуын раслый торган документлар;

л) төп җитештерү мәйданчыгында газ җиһазының, шул исәптән газ балоннары һәм капот асты җиһазының даими тулыландырылып тора торган кимендә 10 комплект склад запаслары булуын раслый торган документлар.

Әлеге пунктның «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән документларны сайлап алуда катнашучы тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә яисә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

2.7. Субсидия күләме транспорт чарасын мотор ягулыгы буларак табигый газ (метан) куллануга яңадан җиһазлау эшен башкара торган субсидия алучы тарафыннан ТЧ хуҗаларына бирелгән, әмма мондый җиһазлау эшләренең гомуми кыйммәтенең (газ баллоны җиһазы кыйммәтен кертеп) иң күбе өчтән бер (әгәр яңадан җиһазландырылган ТЧ хуҗасы (шул исәптән лизинг шартнамәсе нигезендә) физик зат яки юридик зат булса, иң күбе өчтән ике күләмендә һәм әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән максималь күләмнән артмаган күләмдә бирелгән ташламалар күләме суммасы буларак билгеләнә.

2.8. Субсидия бирү нәтиҗәсе - мотор ягулыгы сыйфатында табигый газны (метанны) куллануга яңадан җиһазланган ТС саны.

## III. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Сайлап алуны уздыру турында игълан вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейс рәвешләрен тутыру юлы белән электрон рәвештә төзелә, вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм бердәм порталда заявкалар бирә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла. Моннан тыш, сайлап алуны уздыру турында хәбәр итү турындагы мәгълүмат вәкаләтле орган сайтында заявкалар бирә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә түбәндәгеләр хакында мәгълүмат бирелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкаларны бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану даталары. Шул ук вакытта заявкалар кабул итүне тәмамлау датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 2.8 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

әлеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

заявкалар бирү тәртибен һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

заявкаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, грант күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуда җиңүчегә (җиңүчеләренә) бирелә торган субсидиянең максималь,

минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаган сайлап алу нәтиҗәләре беркетмәсен урнаштыру срогы.

3.2. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында билгеләнгән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкаларны бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 3.9 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

3.3. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра, аларны бирү сайлап алу үткәрү турында игъланда каралган.

«Электрон бюджет» системасында сайлауда катнашучы тарафыннан формалаштырылган заявка сайлап алуда катнашучы яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү датасы булып, заявкага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

3.4. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен түбәндәге документларны үз эченә алган заявканы «Электрон бюджет» системасында урнаштыра:

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә субсидия бирү турында гариза, моңа табигый газны (метанны) мотор ягулыгы буларак куллануга яңадан җиһазландырылган ТЧ санын да кертеп (субсидия бирүнең тәкъдим ителә торган нәтиҗәсе);

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе (сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең электрон цифрлы имзасы) һәм сайлап алуда катнашучының беркетелгән мөһере (булган очракта) белән әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча имзаланган гарантияле хат;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча әлеге Тәртипнең таләпләре нигезендә үткәрелгән эшләр турында гарантия хаты;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турында хисап;

транспорт чаралары хуҗасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәхси мәгълүматларын бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгының күчермәсен теркәп, Россия Федерациясе гражданы – транспорт чаралары хуҗасы паспортының (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсе;

транспорт чараларын теркәү турындагы таныклыкның күчермәсе;

газ баллоны җиһазын сатуны һәм (яки) аны транспорт чараларына урнаштыруны күздә тота торган транспорт чараларын яңадан җиһазландыру турындагы шартнамәнең барлык өстәмә килешүләре белән (әлеге Тәртип белән расланган мондый шартнамәгә таләпләр нигезендә) күчермәсе;

Татарстан Республикасы территориясендә ТЧ эксплуатацияләү фактын раслый торган документның (Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән оешманың ТЧ тапшыру акты яисә шартнамәсе) (ТЧ хуҗасы юридик зат яисә индивидуаль эшкуар булса) күчермәсе;

транспорт чарасын мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ (метан) файдалануга яңадан җиһазлау буенча сарыф ителгән чыгымнарны таркатып язып һәм, ташламаны исәпкә алып, транспорт чарасын яңадан җиһазлау кыйммәтен күрсәтеп, башкарылган эшләр акты күчермәсе;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан транспорт чаралары конструкциясенә үзгәрешләр кертүгә бирелгән рөхсәт кәгазенең күчермәсе;

лизинг бирүченең транспорт чаралары конструкциясенә үзгәреш кертүгә ризалыгы (әгәр транспорт чаралары хуҗасы лизинг бирүче булса);

транспорт чараларын арендалау шартнамәсенең күчермәсе һәм транспорт чаралары хуҗасының транспорт чаралары конструкциясенә (әгәр аренда шартнамәсе төзелгән булса) үзгәреш кертүгә ризалыгы;

урнаштырылган газ баллоны паспортының һәм урнаштырылган газ баллоны җиһазына сертификатның күчермәсе;

двигатель паспортының күчермәсе яки двигательне сатып алу-сату шартнамәсенең күчермәсе (транспорт чаралары моторын алыштырган очракта);

кулланылган газ балоны җиһазына спецификациянең күчермәсе һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләрнең кыйммәтен һәм әлеге эшләргә бирелгән ташламаның исәп-хисабын күрсәтеп, транспорт чараларын яңадан җиһазландыру буенча башкарылган эшләр исемлеге;

урнаштырылган җиһазга сертификат номерын һәм баллон номерын күрсәтеп, двигательне газсыман ягулык белән тәэмин итү өчен транспорт чараларына җиһаз урнаштыру эшләрен башкаручы декларациясенең күчермәсе;

Өнсәсайлап алуда катнашучы һәм транспорт чаралары хуҗасы арасында төзелгән ниятләр турындагы килешүнең күчермәсе (сайлап алуда катнашучы тарафыннан транспорт чаралары хуҗасы һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән яки табигый газ (метан) сатуны гамәлгә ашыручы башка оешма белән өчьяклы килешү төзелгән очракта);

яңадан җиһазландырылган ТЧ хуҗасына  мондый ТЧ эксплуатацияләү һәм аңа хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре турында   инструктаж үткәрелүне раслау;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан, транспорт чараларының идентификация номерын, транспорт чаралары маркасын, транспорт чаралары хуҗасының фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда) яки атамасын, аның элемтәгә керү өчен телефон номерын һәм факттагы яшәү урынын яки урнашу урынын күрсәтеп, транспорт чаралары хуҗасына һәм транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен башкару өчен фактта ташлама бирүне һәм аның күләмен документаль раслау (башкарылган эшләр акты, счет-фактура, чек һәм башкалар);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан транспорт чараларын газ ягулыгына яңадан җиһазландыру эшләрен үткәрү турындагы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хәбәрнамәсен раслый торган документның күчермәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган гариза һәм тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) язмача ризалык;

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан өземтә (кирәк булганда).

Әлеге пунктның сигезенче һәм егерме алтынчы абзацларында күрсәтелгән документларны сайлап алуда катнашучы катнашмаган очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә яисә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

3.5. ТЧ хуҗасына яңадан җиһазлау эшләрен башкаруга сайлап алуда катнашучы тарафыннан фактта ташлама бирүне һәм аның күләмен тикшерү тәртибе  әлеге Тәртипнең 3.4 пунктындагы егерменче абзацында тапшырылган документлар нигезендә вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

3.6. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган  киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә саклаган булырга тиеш түгел.

3.7. Заявкадагы мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

3.8. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка, “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, чират тәртибендә кергән көндә теркәүгә алына.»;

3.9. Сайлап алуда катнашучы заявкага үзгәрешләр кертергә хокуклы:

сайлап алуда катнашучы электрон формада формалаштырылган заявкаларны кире алу турында хәбәрнамәдән һәм алга таба яңа заявка төзелгәннән соң заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр;

заявканы карау этабында вәкаләтле орган хезмәткәрләреннән торучы заявкаларны карау буенча комиссия (алга таба - комиссия) карары буенча гаризаны кире кайтару турында.

Заявкага үзгәрешләр кертү яисә заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.10. Сайлап алуда катнашучы бер сайлап алу барышында төрле ТЧ карата берничә тәкъдим заявка бирергә мөмкин. Сайлап алуның бер катнашучысыннан заявкалар керү көнендә чират тәртибендә «Электрон бюджет» системасында теркәү номерын бирү белән теркәлә. Шул ук вакытта берничә заявка биргән сайлап алуда катнашучы белән сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче һәм субсидия алучы итеп билгеләнгән барлык заявкаларга карата субсидия бирү турында бер килешү төзелә.

3.11. Вәкаләтле орган әлеге Тәртип нигезендә берничә сайлап алу уздырган очракта, алдагы сайлап алуларда катнашкан һәм узган сайлап алулар барышында субсидия алучы булып танылган сайлап алуда катнашучы, вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар нигезендә вәкаләтле орган субсидия бирү турында карар чыгармаган зарядка инфраструктурасы объектларына карата гына чираттагы сайлап алуда катнашу өчен заявка бирергә хокуклы.

3.12. Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап, сайлауның теләсә кайсы катнашучысы, сайлау тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Вәкаләтле органга иң күбе биш гарызнамә җибәрергә хокуклы.

3.13. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 3.12 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп, «Электрон бюджет» системасында аңлатмалар соратып алу көненнән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә.

Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату күрсәтелгән белдерүдә булган мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

3.14. Заявкаларны карау өчен комиссия төзелә. Комиссияне төзү тәртибе һәм комиссия турында нигезләмә вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

3.15. Заявкаларны карау түбәндәге предметка гамәлгә ашырыла:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1, 2.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүе;

документларны бирү һәм аларның әлеге Тәртипнең 3.4, 3.6 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе.

3.16. Вәкаләтле органга һәм комиссиягә «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

«Электрон бюджет» системасында вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганчы бер дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң комиссиягә «Электрон бюджет» системасында бирелгән заявкаларга керү ачыла.

3.17. Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында комиссия тарафыннан заявкаларны карау өчен аларга комиссиягә керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.18. Конкурс комиссиясе, сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны ачу беркетмәсенә имза куя, анда кергән заявкалар турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме (юридик затлар өчен) яисә фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (индивидуаль эшкуарлар өчен);

юридик зат адресы, теркәлү адресы (индивидуаль эшкуарлар өчен);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

3.19. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

3.20. Әгәр заявка сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, ул дөрес дип танылa.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә заявканың туры килүе-килмәве хакында карарлар комиссия тарафыннан сайлап алуда катнашучы заявка белән бергә биргән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләре алынган көндә кабул ителә.

3.21. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итүмәү өчен нигезләр:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1, 2.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

сайлап алуда катнашучы биргән заявкаларның һәм (яки) документларның сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

3.22. Заявканы тулы, һәрьяклап һәм объектив карау максатларында үзләре тапшырган документлар һәм мәгълүмат буенча аңлатмалар алу өчен сайлап алуда катнашучыдан мәгълүмат һәм документлар алырга кирәк булган очракта вәкаләтле орган «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, документлар һәм мәгълүматка карата аңлатуны сайлап алуда катнашучыдан соратып ала, кирәк булса, сайлауда барлык катнашучыларга бертигез дәрәҗәдә җибәрелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауда вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучылар тарафыннан документларга һәм мәгүлүматка карата аңлатма бирү срогын билгели, әлеге срок тиешле рәсми сорау урнаштырылган көннән соң килә торган көннән кимендә өч эш көнен тәшкил итәргә тиеш.

Сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән сроклар эчендә әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә соратыла торган мәгълүматны һәм документларны булдыра һәм «Электрон бюджет» системасына бирә.

Әгәр сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сораугa җавап итеп соратыла торган документларны һәм мәгълүматны, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән срокта тапшырмаган булса, бу турыда мәгълүмат әлеге Тәртипнең 3.26 пунктында каралган заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә кертелә.

3.23. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча тиешле дип танылган заявкаларны ранжировкалау заявкалар керү чиратыннан чыгып комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.24. Сайлап алуда җиңүче булып сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә кергән заявкаларны ранжировкалау нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан төзелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар таныла.

Рейтингта беренче тәртип номеры бирелгән сайлап алуда катнашучыга ул заявкада күрсәткән күләмнең мәгънәсенә тигез, әмма сайлап алуны үткәрү турында игълан итеп билгеләнгән субсидиянең максималь күләменнән югарырак булмаган субсидия күләме бүленә.

Рейтингка кертелгән сайлап алуда һәр чираттагы катнашучыга ул заявкада күрсәткән күләмгә тигез күләмдә субсидия күләме бүленә, ул күрсәткән күләм субсидиянең билгеләнмәгән күләменнән кимрәк йә аңа тигез булса.

Заявкада сайлап алуда катнашучы күрсәткән субсидия күләме бүленмәгән субсидия күләменнән зуррак булган очракта, сайлап алуда катнашучының ризалыгы белән сайлап алуның мондый катнашучысына калган субсидиянең барлык күләме бүленә, сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкада күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсен үзгәртмичә.

3.25. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчене ачыклау максатларында сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

3.26. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

Моннан тыш, әлеге пунктның беренче абзацында каралган беркетмә аңа имза салган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган сайтында урнаштырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3.27 Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе басылып чыкканнан соң биш эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында йә вәкаләтле орган җитәкчесе (яисә ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан раслана торган субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

3.28. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 3.4, 3.6 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

б) субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;

в) агымдагы финанс елында вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын бетерү.

3.29. Сайлау түбәндәге очракларда булмаган дип таныла:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

Сайлап алу узмаган дип танылган, шулай ук сайлап алуны уздырганда әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән субсидияләр бирү максатларында вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары бетерелмәгән очракта, вәкаләтле орган сайлап алуны уздыру турында игъланны кабат урнаштырырга хокуклы.

3.30. Бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында Вәкаләтле орган тарафыннан игълан урнаштыру конкурста катнашучыларның заявкаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә “Электрон бюджет” системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән

квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат туплана.

3.31. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

3.32. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучыларга «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздырмау турында мәгълүмат бирелә.

3.33. Сайлап алу бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштырылган көннән уздырылмаячак дип санала.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия бирү турында килешү «Электрон бюджет» системасында (техник мөмкинлек булганда) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә, вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Кирәк булганда субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү кирәклеге турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган тугыз көн эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән субсидия бирү турында килешүгә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин